**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 25 апрелендәге 1886р номерлы боерыгы**

**Казан шәһәре территориясендә реклама корылмаларын урнаштыруга һәм алардан файдалануга килешүләр төзү хокукына сатулар оештыру турында**

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 26 июнендәге 2544 номерлы «Казан шәһәре территориясендә реклама корылмаларын урнаштыруга һәм алардан файдалануга килешүләр төзү хокукына сатулар үткәрү тәртибе турында»гы карары нигезендә, Казан шәһәре территориясендә реклама корылмаларын урнаштыруга һәм алардан файдалануга килешүләр төзү хокукына сатулар үткәрү максатыннан **йөкләмә бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы реклама һәм мәгълүмат идарәсенә (Ә.Р.Баһаутдинов) Казан шәһәре территориясендә реклама корылмаларын урнаштыруга һәм алардан файдалануга килешүләр төзү хокукына сатулар оештырырга һәм үткәрергә.

2. Казан шәһәре территориясендә реклама корылмаларын урнаштыру һәм файдалану килешүе буенча түләүнең башлангыч (минималь) күләмен исәпләү өчен Р параметрының Казан шәһәре территориясендә реклама корылмасын урнаштыру һәм файдалану килешүе буенча түләүнең башлангыч (минималь) күләмен исәпләү тәртибендә каралган күрсәткечләрен түбәндәгеләр рәвешендә расларга:

- тукталыш пунктының җәмәгать транспортын көтү урынындагы реклама павильоны өчен – 6334 сумга тигез итеп;
- коммуникация күрсәткече өчен – 2238 сумга тигез итеп.

3. Әлеге боерыкны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**